КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1403

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 938 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 938 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 февраль, 168 нче; 2022 ел, 17 июнь, 583 нче; 2023 ел, 4 июль, 785 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген алып бару» сүзләрен «күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга теркәлгән Торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәдә:

1.3 пунктта «күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру,

шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген алып бару» сүзләрен «күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

5.12 пунктның җиденче абзацында «йорт төзүчеләр тарафыннан Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында аларның мәгълүмат урнаштыруына карата таләпләрнең үтәлешен анализлау нәтиҗәләре буенча хисап һәм проект декларациясенә үзгәрешләр кертүне анализлау нәтиҗәләре буенча хисап» сүзләрен «торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында аларның мәгълүмат урнаштыруына карата таләпләренең үтәлешен анализлау нәтиҗәләре буенча хисап» сүзләренә алмаштырырга;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

9.1. Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында, «Интернет» челтәрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка чыганакларда торак-төзелеш кооперативының мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләренә ия гамәлләре турында белешмә елына ике тапкырдан күбрәк урнаштыруны ачыклау.

9.2. Үткән шул ук чор һәм (яисә) үткән календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда бер берәмлек вакыт (ай, квартал) эчендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлешендә (күпфатирлы йортны алга таба карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясында билгеләнгән мәҗбүри таләпләр бозылу фактлары турында торак-төзелеш кооперативының күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзалары акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы адресына гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек биргән ысул белән) яисә оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләр, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» челтәреннән, дәүләт мәгълүмат системаларыннан кергән мәгълүмат саны өч һәм аннан күбрәк тапкырга арту.

9.3. Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүмат өч һәм аннан күбрәк ай дәвамында актуальләштерелмәү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин